ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

“ 16 ” ноябрь 2020 ел № 149

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Генераль планы проекты (алга таба - Проект) буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Иске Чүриле авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларның инициаторы - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- ачык тыңлауларны үткәрү вакыты-2020 елның 25 ноябреннән 2020 елның 30 декабренә кадәр;

- үткәрү урыннары:

ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52, Иске Чүриле мәдәният йорты бинасы;

ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет ур., 30, Штерә авылы мәдәният йорты бинасы;

ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а йорты, Ашабаш авылы клубы бинасы;

ТР, Арча районы, Татар Кадрәге авылы, Аркылы урам, 17 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Венета авылы, Мәктәп ур., 3, Венета башлангыч мәктәбе бинасы;

ТР, Арча районы, Михайловка бистәсе, Тау өсте урамы, 5 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Красная Горка авылы, Бакча урамы, 8 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Ермоловка авылы, Зур Урам, 1 нче йорт каршында.

- фикер алыша торган мәсьәлә буенча гражданнар тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертә торган адрес: ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

4. Ачык тыңлауларда каралырга тиешле Проект экспозициясен 2020 елның 25 ноябрендә ачарга.

4.1. Экспозицияне үткәрү вакыты 2020 елның 25 ноябреннән 2020 елның 27 декабренә кадәр.

4.2. Экспозицияне үткәрү урыны:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru “Территориаль планлаштыру документлары» бүлегендә;

мәгълүмати стендларда:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында (Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт);

ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52, Иске Чүриле мәдәният йорты бинасы;

ТР, Арча районы, Штерә авылы, Советлар ур., 30, Штерә авылы мәдәният йорты бинасы;

ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а йорт, Ашабаш авылы клубы бинасы;

ТР, Арча районы, Татар Кадрәге авылы, Аркылы урам, 17 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Венета авылы, Мәктәп ур., 3, Венета башлангыч мәктәбе бинасы;

ТР, Арча районы, Михайловка поселогы, Тау өсте урамы, 5 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Красная Горка авылы, Бакча урамы, 8 нче йорт каршында;

ТР, Арча районы, Ермоловка авылы, Зур урам, 1 нче йорт каршында.

4.3. Экспозицияне карау вакыты: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт адресы буенча Арча муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында дүшәмбедән җомгага кадәр 8.30 дан 16.30 га кадәр (эшләми торган, бәйрәм көннәреннән тыш).

5. Ачык тыңлауларны оештыручы итеп Арча муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә:

5.1. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларның башлануы турында хәбәрнамәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) 2020 елның 17 ноябрендә бастырып чыгарырга;

5.2. Ачык тыңлауларда катнашучылардан фикер алыша торган Проект буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2020 елның 25 ноябреннән 2020 елның 27 декабренә кадәр түбәндәге рәвешләрдә кабул итәргә:

- электрон рәвештә: Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru);
- язма рәвештә: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт адресы буенча дүшәмбе-җомга көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр һәм 13.30 дан 16.30 га кадәр (эшләми торган, бәйрәм көннәреннән тыш);

5.3. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә әзерләргә;

5.4. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне 2020 елның 30 декабрендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриев